ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2020 ел № 347

«2020 елга 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнар өчен вакытлыча эшләр оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, аны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «2020 елга халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең территориаль программаларын эшләү һәм килештерү турында» Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 04 февралендәге 64 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2020 елга 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнар өчен вакытлыча эшләр оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 191 номерлы карарының 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).
2. Милеккә бәйсез рәвештә Әгерҗе муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, предприятиеләр, оешмалар, район учреждениеләре эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган эш урыннары санын «Әгерҗе районы буенча Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ филиалы белән берлектә исәпләп, балигъ булмаган гражданнарны каникул һәм укудан азат вакытта эшкә урнаштыру өчен вакытлы эшләр оештырырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында

(http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И.И. Шәмсетдинов**

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетынын 2020 елнын 23 июнендәге 191
номерлы карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының 21.10.2020 № 347
карары яна редакциядә)

2020 елда милеккә бәйсез рәвештә Әгерже муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, предприятиеләр, оешмалар, район учреждениеләре эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган эш урыннары санын «Әгерже районы буенча Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ филиалы белән берлектә исәпләп, балигъ булмаган гражданнарны каникул һәм укудан азат вакытта эшкә урнаштыру өчен вакытлы эшләр исемлеге

| № | **Милеккә бәйсез рәвештә предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр исемнәре** | **Эш урыннары саны** |
|---|---|---|
| 1. | Әгерҗе район кулланучылар җәмгыяте | 1 |
| 2. | "Әгерҗе-агрофирмасы" ҖЧҖ | 4 |
| 3. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерже шәһәренең 1 нче гимназиясе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 24 |
| 4. | "Татарстан Республикасы Әгерже шәһәренең 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 46 |
| 5. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерже шәһәренең Таҗи Гыйззәт исемендәге 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 23 |
| 6. | "Татарстан Республикасы Әгерже шәһәренең 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 14 |
| 7. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 10 |
| 8. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бертуган Бубилар исемендәге Иж-Бубый урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 5 |
| 9. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет | 15 |

| | | |
|---|---|---|
| | гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 10. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Омга лицее муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 15 |
| 11. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 5 |
| 12. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын Красный бор урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 17 |
| 13. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 10 |
| | **БАРЛЫГЫ** | **189** |